**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**20 ноябрь 2024 ел** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 20 ноябрендә 9.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2024 елда 1000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Кормаш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 31 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 22 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 22 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда 1000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Кормаш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу).

кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина